Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 ноябрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Пановка авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыеннарын билгеләргә:

1.1. Новоселек авылында. 2019 елның 24 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Елга арты урамы буенча 12 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Пановка авыл җирлеге Новоселек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- җирлек территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Пановка авылында гражданнар җыены дүрт этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 26 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта 1 Май урамы, 12 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Беренче Май урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 27 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2019 елның 3 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк

бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тукай урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының дүртенче этабы 2019 елның 5 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Мәктәп урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;

- җирлек территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев